ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» июненнән № ____

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 03 маендагы 207 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 226 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елның 1 маеннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 351 номерлы, 2024 елның 16 маендагы 143 номерлы, 2024 елның

30 октябрендәге 270 номерлы карарларындагы төзәтмәләр белән) билгеләнгән тәртиптә бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,1 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 15 389 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 351 номерлы, 2024 елның 16 маендагы 143 номерлы, 2024 елның 30 октябрендәге 270 номерлы карарларындагы төзәтмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктчаның 3 пунктында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктчаның 4 пунктында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский